СОВЕТ
БОЛЬШЕШУРНЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ ШУРНЯК
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 18 ”19” февраль 2021 ел

2020 елнын 16 декабрендэ кабул ителгэн " 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллардагы план чорына Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Шүрнәк авыл җирлегенен бюджеты турындагы" 11 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Алабуга муниципаль районының Олы Шүрнәк авыл җирлегендә бюджет процессы турында» гы нигезләмә нигезендә һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9 статьясына таянып, Олы Шүрнәк авыл җирлеге Советы

Карар итте:

1. Олы Шүрнәк авыл җирлеге Советының 2020 елның 16 декабрендә кабул ителгән 11 номерлы «Олы Шүрнәк авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022, 2023 еллардагы план чорына бюджеты турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяда:

*1 өлеш*

5 нче кушымтаны «2021 елга авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» яңа редакциядә бәян итәргә;

*2 өлеш*

6 нчы кушымтаны «2021 елга бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм программа булмаган эшчәнлек юнәлешләре), төркемнәре буенча җирлек бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бүлү» яңа редакциядә бәян итәргә»;

*3 өлеш*

7 нче кушымтаны «2021 елга бюджет чыгымнарының максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре буенча

җирлек бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бүлү» яңа редакциядә бәян итәргә;

2) түбәндәге эчтәлекле 8 статья өстәргә:

«Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Олы Шүрнәк авыл җирлеге бюджетыннан 2021 елга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетына тапшырыла торган бюджетара трансфертларның күләме 19,0 мең сум күләмендә, әлеге карарның 8 нче кушымтасы нигезендә бүленеп, раслау турында»;

«2021 елга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Шүрнәк авыл җирлеге бюджетыннан тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» 8 нче кушымтасын өстәргә;

5) 8 – 11 статьяларны 9 – 12 статьялар диеп санарга.

2. Әлеге карар массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылып чыгарга тиеш.

Рәис Н.И. Мельников